ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# «Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыру турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2023 елның 19 октябрендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыру турында» 2004 елның 26 июлендәге 43-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 7 (I өлеш); 2007, № 8; 2009, № 6, № 9 – 10; 2011, № 4 (I өлеш), № 10 (I өлеш); 2012, № 3; 2014, № 1 – 2; 2015, № 4, № 10 (I өлеш); 2016, № 10; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2019, № 49 (I өлеш); 2020, № 1 (I өлеш), № 94 (I өлеш); 2021, № 77 (I өлеш); 2023, № 27 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 статьяга түбәндәге эчтәлекле $7^2$ пункт өстәргә:

«$7^2$) хосусыйлаштырылганда газ бүлү челтәрләренә, газ куллану челтәрләренә һәм мондый челтәрләрнең газ кулланучыларны газ белән тәэмин итү өчен кулланыла торган объектларына салынган эксплуатация йөкләмәләренең үтәлешен тикшереп тору тәртибен билгели;»;

2) 8 статьяның 2 өлешендә:

а) түбәндәге эчтәлекле яңа ундүртенче абзац өстәргә:

«Газ бүлү челтәрләре, газ куллану челтәрләре һәм мондый челтәрләрнең газ кулланучыларны газ белән тәэмин итү өчен кулланыла торган объектлары хосусыйлаштырылган очракта, аларны эксплуатация йөкләмәләре белән чикләп тору хосусыйлаштыру шартлары турындагы карарга мөһим шарт буларак кертелергә тиеш.»;

б) ундүртенче һәм унбишенче абзацларны тиешенчә унбишенче һәм уналтынчы абзацлар дип санарга;

3) 10 статьяда:

а) исемендә «Акционер җәмгыять акцияләрен, җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятьнең устав капиталындагы өлешләрен, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларының (тарихи һәм мәдәни ядкәрләренең) бердәм дәүләт реестрына кертелгән мәдәни мирас объектларын» сүзләрен «Дәүләт мөлкәтен» сүзләренә алмаштырырга;

б) 1 өлештә:

беренче абзацта «(тарихи һәм мәдәни ядкәрләренең) бердәм дәүләт реестрына кертелгән мәдәни мирас объектларын (алга таба – мәдәни мирас объектлары)» сүзләрен «(тарихи һәм мәдәни ядкарьләренең) бердәм дәүләт реестрына кертелгән мәдәни мирас объектларын (алга таба – мәдәни мирас объектлары), газ бүлү челтәрләрен, газ куллану челтәрләрен һәм мондый челтәрләр объектларын» сүзләренә алмаштырырга;

алтынчы абзацта «объектларына» сүзеннән соң «, газ бүлү челтәрләренә, газ куллану челтәрләренә һәм мондый челтәрләр объектларына» сүзләрен өстәргә;

җиденче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни ядкарьләре) турында» 2002 елның 25 июнендәге 73-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә торышы канәгатьләнмәслек дип танылган мәдәни мирас объектын әлеге Федераль законда билгеләнгән тәртиптә саклап калу буенча эшләр үткәрү;»;

түбәндәге эчтәлекле яңа сигезенче абзац өстәргә:

«Дәүләт мөлкәтен һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында» 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы Федераль законның 29 статьясы нигезендә башка шартлар.»;

сигезенче һәм тугызынчы абзацларны тиешенчә тугызынчы һәм унынчы абзацлар дип санарга;

4) 15 статьяның 1 өлешендә «күрсәтелгән объектлардан файдалана алуны тәэмин итүгә таләпләр» сүзләрен «мондый объектлардан файдалана алуны тәэмин итүгә таләпләр, мондый объектларда һәм аларның территорияләрендә тышкы реклама урнаштыруга таләпләр, шулай ук мәдәни мирас объекты турында мәгълүматы булган язмалар һәм билгеләр урнаштыруга таләпләр» сүзләренә алмаштырырга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе Р.Н. Миңнеханов

ГОМУМИ БҮЛЕК ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2023 ел, 02 ноябрь
№ 101-ТРЗ